«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясе буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында»Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 7 апрелендәге 90 номерлы карары

"Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында" 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 2 апрелендәге 69 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясе буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а)2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2.1 Башкарма комитет

1) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә норматив хокукый актлар кабул итә;

2) муниципаль берәмлекнең башкарма-боеру органы тарафыннан раслана торган даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын әзерләү тәртибен билгели;

3) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль заказчысы функцияләрен башкара, муниципаль контракт төзи һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирә;

4) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурсны оештыручы функцияләрен башкара, мондый конкурста катнашуга заявкалар критерийларын бәяләү өчен шкала билгели, конкурс документациясен раслый, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукын бирә;

5) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукына ачык конкурс уздыру турында хәбәрнамәне Апас муниципаль районының "Интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру тәртибен билгели;

6)даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукына ачык конкурста катнашуга заявка рәвешен һәм әлеге заявканың эчтәлегенә (шул исәптән ачык конкурста катнашучы тәкъдименең тасвирламасына)таләпләрне билгели;

7) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын алып бару тәртибен, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча гамәлгә ашырыла торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның төрен үзгәртү турында белешмәләрне аңа кертү тәртибен раслый, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын алып бара;

8)даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату тәртибен (шул исәптән юридик затларның,

индивидуаль эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның әлеге маршрутларны билгеләү, үзгәртү йә туктату турындагы гаризаларын карау тәртибен, шулай ук әлеге маршрутларны билгеләүдән йә үзгәртүдән баш тарту өчен нигезләрне, әлеге маршрутларны туктату өчен нигезләрне) раслый, муниципаль маршрутларны билгели, үзгәртә һәм юкка чыгара даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутлары;

9) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары буларак файдаланырга рөхсәт ителә торган Апас муниципаль районы муниципаль берәмлекләре территорияләрендә урнашкан тукталыш пунктлары исемлеген билгели;

10)Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча Апас муниципаль районы муниципаль берәмлекләре территорияләрендә тукталыш пунктлары билгеләү буенча тәкъдимнәр җибәрә;

11)кирәк булганда даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга таләпләр билгели;

12)автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль кысаларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяли;

13) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән җирле үзидарә органнары компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

б) 5.3 пунктта "алыш-бирешне гамәлгә ашыру турында таныклык бирелде" сүзләрен "алыш-бирешне гамәлгә ашыру хокукы бирелде" сүзләренә, "шундый таныклык" сүзләрен "шундый хокуклы"сүзләренә алмаштырырга.;

в) 5.3 пунктта " гамәлгә ашыру турында таныклыклар бирелде "сүзләрен" гамәлгә ашыру хокукы бирелде "сүзләренә," мондый таныклыкларны һәм әлеге маршрутларның карталарын "сүзләрен" шундый хокуклы "сүзләренә алмаштырырга.;

г) 7.2 пунктта "даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык" сүзләрен "маршрутның тиешле төре реестрына язылу"сүзләренә алмаштырырга.;

д)8 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукын бирү һәм тиешле маршрут карталарын бирү»

8.1.Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы әлеге маршрутларны билгеләгән Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан бирелә.

8.2. даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукы

(алга таба - ачык конкурс) "Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - Федераль закон) билгеләнгән тәртиптә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукы ачык конкурс нәтиҗәләре буенча бирелә.»;

е)10 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Бирелгән хокукның гамәлдә булуын туктату

«10.1. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруның бирелгән хокукының гамәлдә булуы Федераль законның 29 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән шартларның берсе булса да Федераль законның 29 статьясындагы 2-4 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә туктатыла.

10.2.Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукын биргән Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитеты Федераль законның 29 статьясындагы 5 өлешендә каралган берәр хәл килеп чыкканда әлеге хокукның гамәлдә булмавы турында гариза белән судка мөрәҗәгать итә.».

ж) 11.1 пунктта «йә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән» сүзләрен «йә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукы бирелгән» сүзләренә, «әлеге таныклыкны биргән» сүзләрен «пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукын биргән»сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карар, әлеге карарның 1 пунктындагы «а», «д», «е», «ж» пунктчаларыннан тыш, басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Әлеге карарның 1 пунктындагы «а», «д», «е», «ж» пунктлары 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

Җитәкче                                                                                    Б.Н. Әхмәтҗанов

